ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

«КӨЗГЕ»

СЕНТЯБРЬ, 2016нче ел

№1(20)

## ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!





Беренче сентябрь иртәсе кояшлы да, болытлы да, яңгырлы да була. Шулай да андый иртәләрнең һәрберсе күңелгә кояшлы булып иңә. Ничек шулай булмасын! Белем иле юлыннан беренче адымын ясый бит бала, киләчәгенә юл яра! Ул матур итеп киенгән, бер кулында — портфель, икенчесендә — чәчәкләр. Әлеге көн һәр кешенең дә диярлек күңелендә сакланадыр. Мәктәптә уку еллары безнең тормышыбызда зур урын алып тора. Мәктәпне тәмамлаган чакта без инде тагын да зуррак юлга адым атлар кешеләр булып тәрбияләнеп чыгабыз. Әлеге юллар безне дөньяның төрле төбәкләренә алып китәргә сәләтле.

Әйе, бала мәктәптә матурлыкка омтыла, якты киләчәгенә кул сузып бара! Алдында — биек үрләр, шул үрләрне яулый алса гына, ул бәхетле булачак. Аңа шушы үрләрне яулауда, белем алуда укытучы ярдәмгә килә.

Укытучы! Изге бер сүз ул. Һәр кеше бу сүзнең мәгънәсенә төшенә.Укытучы бөтен көчен биреп, бөтен яхшылыкны укучыларының Күңеленә сеңдерергә тырыша: җирне, тормышны аңларга, аны яратырга өйрәтә.

Укучыларны, аларның әти-әниләрен һәм укытучыларын чын күңелдән бүгенге Белем бәйрәме белән тәбрик итәбез! Укуыгызда уңышлар, ныклы сәламәтлек, яңа белемнәр алган вакытта күзләрегездә очкыннар ялтырап торуын телибез! Өстә әйтелгән теләкләргә өстәп тагын шуны әйтәсебез килә. Иң ныклы, иң яхшы, иң истә кала торган белемнәр - үз туган телеңдә алынган белемнәр! Без моны бик яхшы беләбез, күп еллык тәҗрибәбез моңа дәлил булып тора!

Чакыра, тагын чакыра
Кыңгырау сыйныфларга.
Бүгеннән — белем көненнән —
Уку елын башларга.

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Белем бәйрәме | 2 |
| «Тынычлык» сыйныф сәгатьәре | 3 |
| Якыннан тапышыйк | 4 |
| Кайда рәхәт, кайда хәсрәт | 4 |
| Бакчабыз да бакчабыз | 4 |
| Варислар туган көне | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |

# «Тынычлык»
# Мәктәптә беренче сыйныф сәгатьләре

Яңа уку елы башлануын хәбәр итеп яңгыраган кыңгырау укучыларны классларга дәште. Чыгарылыш сыйныф укучылары быел беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән 7 сабыйны үз классларына озатты. Яңа уку елының беренче тәрбия сәгате тынычлык темасына багышланды. Агымдагы елда мәктәптә 98 бала парта артына утырды. Беренче класста 7 бала укыса, тугызынчыда – ундүрт. Узган уку елында мәктәпне тәмамлаган 6 укучының дүртесе югары уку йортларында белемнәрен дәвам итәләр. Мәктәптә милли гореф-гадәтләрне саклауга һәм үстерүгә зур әһәмият бирелә, оештырылган барлык мәдәни чаралар да саф татар телендә уздырыла

Менә шулай, тагын бер уку елына аяк бастык. Сау-исән булып барчабызга да аның тәмамлануын да күрергә язсын иде


***Шарапова Ләйсән,***


*10нче сыйныф.*

## Фоторепортаж








# Якыннан танышыйк





**Укучыларның сорауларына татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сафиуллина Резеда Дамировна җавап бирә.**

*- Ни өчен сез укытучы һөнәрен сайладыгыз ?*

-Олы хөрмәткә лаек укытучы һөнәре мине балачактан укүзенә җәлеп итте.

*- Сез кайсы дәресне ныграк яраттыгыз?*

- Әдәбият дәресләрен,химияне.

*-Үзегезнең яраткан укытучыларыгызны хәтерлисезме?*

-Кем генә бу исемне зур хөрмәт белән телгә алмый икән?

Һәркайсыбызның иң матур хатирәләре,шатлыкборчулары, беренче дулкынланулары нәкъ менә мәктәп һәм укытучы белән бәйле.

*-Начар билге алсагыз кайгыра идегезме?*

-Начар билге бик алмадым. Бер тапкыр шигырь ятламау сәбәпле «3»ле алган идем. Шул көнне мәктәбебезгә кунаклар килгән иде, мин өйгә эш бирмәгәннәр диеп мәктәпкә килдем. Ә ой эшенә шигырь ятларга булган икән. Мәктәпкә килгән кунаклар алдында шул шигырьне начар сөйләгәнгә «3»ле куйган иделәр.

*- Укытучы эшендә иң ошаганы нәрсә?*

-.Укучылар белән аралашу миңа чиксез шатлык, рәхәтлек китерә, чөнки мин аларга, алар миңа кирәк.

*-Сезнең яраткан китабыгыз?*

- Зифа Кадыйрова әсәрләре.

*- Сезгә кайсы төс ошый?*

- Бөтен булган ачык төсләр.

*- Укучыларга һәм укытучыларга теләкләрегез?*

Һәр таңны сау-сәламәт каршылагыз,замана авырлыклары, күңел төшенкелеге сезне ччитләтеп үтсен, бәхетле булыгыз!

## Кайда рәхәт, кайда хәсрәт

1 сентябрьдә Татарстанда 38 меңгә якын бала парта арасына утырды, шуның 3900е – беренче класслар. Республикада аз комплектлы 12 авыл мәктәбе ябылган, шундый язмыш тагын 176 белем йортын көтә. Укучылары аз мәктәпләр бюджетка зур йөк булып төшә. Шәһәр мәктәбендә бер баланы ел буе укыту – 27 мең булса, аз комплектлы мәктәптә 240 мең сум икән. Мәктәбен ябасың да, проблема үзеннән-үзе хәл ителә. Менә шулай уйлый түрәләр. Соңгы вакытта мәктәпне ябарга тагын бер сәбәп килеп чыкты, янәсе, авыл мәктәбендәге шартлар мәгариф стандартларына туры килми. Ә нигә аларны туры килерлек итмәскә, шуның өстендә эшләмәскә??? Бөтен нәрсә киләчәк буын өчен, дибез бит. Ә монда, киресенчә, стандартка туры китерү өчен нәрсәдер эшләү урынына, стандартка туры килмәгәнгә мәктәбе ябыла...

Без мәктәбебезнең киләчәге якты, өметле булсын, укучылар саны артсын, дигән теләктә калабыз.






***Актуаль мәсьәлә***

# Грипкка каршы вакцинация башланды



Йогышлы чирләр структурасында 95 процентны биләп торучы грипп һәм кискен респиратор йогышлы авырулар халык сәламәтлегенә җитди зыян сала. Табиблар сүзләренә караганда, грипп үзе түгел, ә ул китергән өзлегүләр куркыныч. 1997-1998 елларда Татарстанда грипп белән авыручылар саны 300- 400 меңгә җиткән, соңгы елларда ул 3- 4 мең кеше тәшкил итә. Грипкка каршы түләүсез вакцинация укытучыларга, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, медицина хезмәткәрләренә, 60 яшьтән өлкән кешеләргә ясала. Аллергия реакциясе булган һәм тавык аксымын кабул итә алмаган кешеләргә вакцинация ясау киңәш ителми.

–Әгәр сездә авыру билгеләре: тән температурасының күтәрелүе, тирләү, хәлсезлек, буыннар, мускуллар, баш авырту, көчле (авырту белән) ютәл, томау, гиперемия, авыз эче һәм тамакның кипшенүе күзәтелсә, белеп торыгыз – Сез грипп эләктергәнсез. Үз белдегең белән дәваланмаска, кичекмәстән табибка күренергә кирәк,-дип кисәтә бу уңайдан Гүзәлия Маликова.

Вакцина ясату (профилактика) бу авырудан саклануның кулай чарасы булып тора. Хезмәт коллективларында хезмәткәрләрнең 70-80%на вакцина ясау бу коллективта авыру ихтималын нык чикли.

–Грипкка каршы вакцинаны, гадәттә, ел саен октябрь-ноябрь айларында ясыйлар. Вакцина ясалгач, 2 атнадан соң иммунитет көчәя һәм грипп вирусына каршы антитәнчекләр эшләп чыгарыла,-ди баш табиб урынбасары.– Грипптан саклану өчен кулларны һәрвакыт сабынлап юарга, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга: туйганчы йокларга, файдалы ризыклар ашарга, актив булырга, күбрәк сыеклык эчәргә, кеше күп җыела торган җирләрдә булмаска тырышырга, саф һавада күбрәк йөрергә, сулыш органнарын саклау өчен маскалар киярргә.

***Абдрахманова Рәзилә***

# *Эш эшләсәң эш көне– тук булырсың кыш көне*

Кемгә ничектер, минем үземә көз көне бакчада эшләү бик ошый. Ни өчен дигәндә, көзге муллыкны җыеп алу - нинди зур куаныч. Кишер түтәлен казып, рәтләргә салабыз да, сабакларын кисеп, чиләкләргә тутырабыз. Кайберәүләр аларны ашханә подволына кертә. Кәбестә күчәннәрен зурлар урнаштыра. Бергәләшеп җир кишәрлеген чүпләрдән арындырабыз.

Мәктәп бакчасында үскән яшелчәләрдән пешкән ашны ашау, салатлар белән сыйлану укучыларга бик ошый. ”Хезмәте барның ашы да бар”, - дип, борынгылар бик дөрес әйткәннәр.

***Таһирова Гайшә***



# Көлке хикмәте

*Мәзәк – борынгы заманнарда ук туып, безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр. Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә.*

*Мәзәкләр, гадәттә, мәҗлесләрдә, күмәк ял вакытларында җыелган кешеләрне бер көлдереп алу, аларның күңелен ачу максатында сөйләнәләр. Мәзәк – күңел ачкычы" дигән гыйбарә дә жанрның әнә шундый вазифасына ишарә итә.*

****

Вәли мәктәптән өенә кайтып кергәч:
- Җитте! Бүтән бу мәктәбегезгә ике аягымның берсен дә атламыйм!
- Нишләп?
- Укый белмим, яза белмим, ә сөйләшеп утырырга рөхсәт итмиләр.



****

- Айнур, минем компьютерым эшләми.
- Анда бер зур төймә бар, аңа басып карадыңмы?
- Әйе, барыбер эшләми.
- Розеткага тыкканмы?
- Белмим, хәзер шырпы кабызам да карыйм.
- Ә шырпы нигә?
- Бездә утны сүндерделәр...

****

Интернетта ике вирус очрашкан ди:
- Кая бардың?
- Әй, татар сайтларын агуларга барган идем лә...
- Нәрсә, барып чыкмадымыни?
- Әй, аларны Латиница дигән бер бик зәһәр вирус агулап бетергән икән инде...



****

ВУЗда экзамен бара. Профессор:
- Сезгә бер авыр сорау биримме, әллә ике җиңелнеме?
- Бер авырны.
- Алайса менә мондый сорау, җавап бир: Җир шарында мамонтлар беренче мәртәбә кайда табылган?
- Казанның Бауман урамында.
- Нигә анда?
- Ә монысы инде икенче сорау!

****

Әтисе улына:
- Улым, син үсеп җиттең инде, кем булырга уйлыйсың?
- Әти, мин Кыш бабай булырмын ахры!
- Нишләп? !
- Нишләп дип, чөнки ул Яңа елга кадәр бер атна һәм Яңа елдан соң бер атна гына эшли.

****

Автомәктәптә имтихан бара:
- Двигатель ничек эшли?
- Үз сүзләрем белән мөмкинме?
- Әлбәттә!
- Вжжжж! Вжжжж! Вжжжж!



****

Печән чапканда ике дус сөйләшә. Берсе икенчесеннән сорый:
-Син кемгә чабасың? - ди.
- Картайган көнемдә кешегә чабып йөрмәм инде, үземә чабам, - ди тегесе.
- Ә мин сыерга чабам, - ди дусты, серле генә елмаеп.

**3 сентябрьдә Россиядә Террорчылыкка каршы көрәш көне билгеләп үтелә. 2004 ел-ның 1 сентябрь көнендә Беслан шәһәре мәктәбен террорчылар басып алганын һәркем хәтерлидер... Нәтиҗәдә, 1200дән артык кеше тоткынлыкта калып, аларның 330ы һәлак булды. Шунысы кызганыч, алар арасында 180 (!) бала...**

Хәзерге вакытта бөтен дөньяда террорчылыкка каршы хәрәкәт активлаша төште.Укучыларыбыз «Ак торналар» акциясендә бик теләп катнаштылар .Беслан шәһәрендәге канкойгыч вакыйга да, 11 сентябрь фаҗигасе дә кабатланырга тиеш түгел.






15 сентябрь көнне мәктәбебездә Татарстан варислары берлегенең туган көнен билгеләп үттек. Быел аңа 26 ел тулды. Станцияләр буенча уен-сәяхәттә 5,6,7 сыйныф укучылары бик теләп катнаштылар. Барлыгы җиде станция урнашкан иде. Ул— “Ашыгыч ярдәм” , “Уен” , “Кунакчыл”, “Дару үләннәре”, “Табышмаклар” , “Спорт”, “Җыр” станцияләре. Һәрбер станциянең үз алып баручысы беркетелде. Барлыгы өч отряд катнашты. Һәрбер отряд үз исеме, капитаны, девизы һәм җыры белән таныштырды. Барлык отряд та станциядәге җәзаларны үтәп, финишка юл тотты. Уенда актив катнашучы отрядлар грамота белән бүләкләнде. Бәйрәм һәркемнең күңеленә хуш килде.

## Бәйрәмнән фоторепортаж






5 сентябрьдән 11 сентябрьгә кадәр республикабызда эчкечелеккә каршы акция булып үтте. Шул акция кысаларында үткәрелгән **“Айыклык бәйрәме”** ндә укучыларыбыз бик теләп катнаштылар.





## Мастер-класс «Топиарий» своими руками

**Необходимый материал:**

- кашпо, газеты, нитки, салфетки, степлер, ножницы, клей (лучше подойдет клей-карандаш)



1. Берем расправленную газету и сминаем ее вдоль.
2. Плотно обматываем мятой газетой вершину ствола.
3. Делаем несколько слоев, формируем шар из газет. Размер шара примерно соответствует размеру кашпо .Полученный шар закрепляем нитками.
4. Берем салфетку, складываем пополам и еще раз пополам.
5. По центру полученный квадратик скрепляем степлером.
6. В каждом цветке получилось 16 слоев. Берем верхний слой кружка, поднимем вверх и сжимаем его к центру произвольно.
7. Наклеиваем цветы на газетный шарик. Лучше начать от ствола (снизу вверх).Наносим клей на газетный шарике и приклеиваем цветок.
8. **Желаю успехов в ваших творческих делах!Спасибо за внимание!**

## Сентябрь аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Васильев Руслан, Абдрахманов Рифат, Вәлиуллина Әнисә, Хисматова Зәринә, Никулин Тимур, Закирова Гөлинә, Ибраһимов Зөлфәт, Кәбирова Дилбәр, Хисматов Рәсим, Хайбуллина Алсу, Замалеев Алмаз, Хайруллин Булат, Вәгыйзова Ләйсән, Масгутов Илназ!

Сезне барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , исәнлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын.



**Бу сан өчен мәктәпнең “Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз

**Дизайнер**: Абдрахманова Рәзилә

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Гайсина Гөлшат

Абдрахманова Рәзилә

Таһирова Гайшә

Садртдинова Рузилә